АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«____» ________________20 г.** № __________

Казан ш.

**Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш Агентлыгындагы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына квалификация таләпләрен раслау турында**

“Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында”гы 27.07.2014 ел, №79-ФЗ Федераль законның 12 нче статьясы һәм “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында”гы 16.01.2003 ел, № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 10 нчы статьясы нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгындагы дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи йөкләмәләрен башкару өчен кирәкле булган профессиональ белем алу дәрәҗәсенә, дәүләт граждан хезмәте стажына һәм белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына (тәҗрибәсенә), профессиональ белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләрен кушымта буенча расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Л.Г. Якупов

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш
агентлыгының
__________2014 ел,
№ ___ боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгындагы дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи йөкләмәләрен башкару өчен кирәкле булган профессиональ белем алу дәрәҗәсенә, дәүләт граждан хезмәтенең стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына (тәҗрибәсенә), профессиональ белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре**

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгында түбәндәге **категорияләр һәм вазыйфалар төркемнәре буенча** дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүчеләрнең вазыйфаи йөкләмәләрен башкару өчен кирәкле булган профессиональ белем алу дәрәҗәсенә, дәүләт граждан хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына (тәҗрибәсенә), профессиональ белемнәренә һәм күнекмәләренә карата квалификация таләпләре:

**1. “Җитәкчеләр” категориясендәге вазыйфаларның төп төркеме:**

1.1. Профессиональ белем алу дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре: югары белемгә ия булу.

1.2. Дәүләт граждан хезмәте стажына яисә белгечлек буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре: дәүләт хезмәте вазыйфаларындагы әйдәп баручы яисә өлкән төркемнәрдә ике елдан да азрак булмаган дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча өч елдан да ким булмаган эш стажы.

1.3. Профессиональ белемнәргә һәм күнекмәләргә куелучы квалификация таләпләре:

белергә тиешләр:

- Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, дәүләт граждан хезмәте өлкәсендәге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, федераль законнарны, үз вазыйфаи йөкләмәләренә карата Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе Президенты указларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын, үз вазыйфаи йөкләмәләренә карата башка төр норматив хокукый актларны;
- икътисадның, базар мөнәсәбәтләре шартларында хезмәтне, җитештерүне һәм идарә итүне оештыруның нигезләрен;
- җитештерүнең, хезмәтнең һәм идарә итүнең принципларын һәм планлаштыру, фаразлау һәм фәнни оештыру юлларын;
- хезмәттәге эш тәртибен;
- массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү формаларын һәм ысулларын;
- эшлекле этикет кагыйдәләрен;
- эш башкаруның нигезләрен;

күнекмәләре:

- таләпчән, энергияле, үҗәт булу;
- кешеләргә карата җаваплы, ярдәмчел һәм дуслык мөнәсәбәтендә булу;
- үз профессиональ белемнәренең дәрәҗәсен күтәрү;
- лидер күнекмәләренә ия булу;
- оештыру сәләтләренә, зур коллектив белән җитәкчелек итү сәләтенә ия булу;
- максатларны һәм бурычларны кую, кул астындагыларның эшчәнлеген стимуллаштыру һәм мотивацияләү сәләтенә ия булу;
- үз фикерләреңне төгәл һәм хатасыз итеп телдән һәм язмача формада җиткерә белү;
- халык алдында чыгыш ясау күнекмәләренә ия булу;
- хезмәткәрләрне дөрес итеп сайлап ала белү;
- төркемдә эшли белү;
- мөстәкыйль һәм бик тиз рәвештә карарлар кабул итә белү;
- анык эшләрнең планын эшли белү;
- эшлекле сөйләшүләрне алып бара белү;
- компьютер һәм башка оештыру техникасы, шулай ук кирәкле программалар белән идарә итә белү;
- хезмәт нәтиҗәләренә ирешүне стимуллаштыра белү;
- кул астындагылар алдына ирешә алырлык бурычлар куя белү;
- тактик максатларны стратегик максатларга буйсындыра белү;
- анализ ясау сәләтләренә ия булу;
- үзлектән үсү сәләтләренә ия булу;
- куелган бурычларны чишүгә иҗади якын килә белү.

**2. “Җитәкчеләр” категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркеме:**

2.1. Профессиональ белем алу дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре: югары белемгә ия булу.

2.2. Дәүләт граждан хезмәте стажына яисә белгечлек буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре: дәүләт хезмәте вазыйфаларының өлкән яисә кече төркемнәрендә бер елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы.

2.3. Профессиональ белемнәргә һәм күнекмәләргә куелучы квалификация таләпләре:

белергә тиешләр:

- Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, дәүләт граждан хезмәте өлкәсендәге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, федераль законнарны, үз вазыйфаи йөкләмәләренә карата Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе Президенты указларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын, үз вазыйфаи йөкләмәләренә карата башка төр норматив хокукый актларны;
- икътисадның, базар мөнәсәбәтләре шартларында хезмәтне, җитештерүне һәм идарә итүне оештыруның нигезләрен;

- җитештерүнең, хезмәтнең һәм идарә итүнең принципларын һәм планлаштыру, фаразлау һәм фәнни оештыру юлларын;

- эшлекле этикет кагыйдәләрен;

- эш башкаруның нигезләрен;

күнекмәләре:

- үз профессиональ белемнәренең дәрәҗәсен күтәрү;

- оештыру сәләтенә, зур коллектив белән җитәкчелек итү сәләтенә ия булу;

- максатларны һәм бурычларны кую, кул астындагыларның эшчәнлеген стимуллаштыру һәм мотивацияләү сәләтенә ия булу;

- үз фикерләреңне төгәл һәм хатасыз итеп телдән һәм язмача формада җиткерә белү;

- мөстәкыйль һәм бик тиз рәвештә карарлар кабул итә белү;

- кул астындагылар алдына ирешергә мөмкин булган бурычларны куя белү;

- тактик максатларны стратегик максатларга буйсындыра белү;

- анализ ясау сәләтләренә ия булу.

**3. “Белгечләр” категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркеме:**

3.1. Профессиональ белем алу дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре: югары белемгә ия булу.

3.2. Дәүләт граждан хезмәте стажына яисә белгечлек буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре: дәүләт хезмәте вазыйфаларының өлкән яисә кече төркемнәрендә бер елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы.

3.3. Профессиональ белемнәргә һәм күнекмәләргә куелучы квалификация таләпләре:

белергә тиешләр:

- Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, дәүләт граждан хезмәте өлкәсендәге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, федераль законнарны, үз вазыйфаи йөкләмәләренә карата Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе Президенты указларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын, үз вазыйфаи йөкләмәләренә карата башка төр норматив хокукый актларны;

- җитештерүнең, хезмәтнең һәм идарә итүнең принципларын һәм планлаштыру, фаразлау һәм фәнни оештыру юлларын;

- эшлекле этикет кагыйдәләрен;

- хезмәттәге эш тәртибен;

күнекмәләре:

- кешеләргә карата җаваплы, ярдәмчел һәм дуслык мөнәсәбәтендә булу;

- үз профессиональ белемнәренең дәрәҗәсен күтәрү;

- үз фикерләреңне төгәл һәм хатасыз итеп телдән һәм язмача формада җиткерә белү;

- эшлекле хат әзерләү күнекмәләренә ия булу;

- төркемдә эшли белү;

- компьютер һәм башка оештыру техникасы, шулай ук кирәкле программалар белән идарә итә белү;

- анализ ясау сәләтләренә ия булу;

- үзлектән үсү сәләтләренә ия булу;
- куелган бурычларны чишүгә иҗади якын килә белү.

**4. “Тәэмин итүче белгечләр” категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркеме:**

4.1. Профессиональ белем алу дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре:
югары белемгә ия булу.

4.2. Дәүләт граждан хезмәте стажына яисә белгечлек буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре: дәүләт хезмәте вазыйфаларының өлкән яисә кече төркемнәрендә бер елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы.

4.3. Профессиональ белемнәргә һәм күнекмәләргә куелучы квалификация таләпләре:

белергә тиешләр:

- Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, дәүләт граждан хезмәте өлкәсендәге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, федераль законнарны, үз вазыйфаи йөкләмәләренә карата Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе Президенты указларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын, үз вазыйфаи йөкләмәләренә карата башка төр норматив хокукый актларны;
- җитештерүнең, хезмәтнең һәм идарә итүнең принципларын һәм планлаштыру, фаразлау һәм фәнни оештыру юлларын;
- эшлекле этикет кагыйдәләрен;
- хезмәттәге тәртип кагыйдәләрен;

күнекмәләре:

- кешеләргә карата җаваплы, ярдәмчел һәм дуслык мөнәсәбәтендә булу;
- үз профессиональ белемнәренең дәрәҗәсен күтәрү;
- үз фикерләреңне төгәл һәм хатасыз итеп телдән һәм язмача формада җиткерә белү;
- эшлекле хат әзерләү күнекмәләренә ия булу;
- төркемдә эшли белү;
- компьютер һәм башка оештыру техникасы, шулай ук кирәкле программалар белән идарә итә белү;
- анализ ясау сәләтләренә ия булу;
- үзлектән үсү сәләтләренә ия булу;
- куелган бурычларны чишүгә карата иҗади якын килә белү.